Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чытырчы авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

29.08.2023 ел № 35/1

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чытырчы авыл җирлеге Советының
2019 елның 05 июнендәге
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
«Чытырчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә
муниципаль хезмәт турында»гы 67/1 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль законы, Чистай муниципаль районының Чытырчы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чытырчы авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чытырчы авыл җирлеге Советының 2019 елның 5 июнендәге 67/1 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чытырчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмә»нең 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Мәнфәгатьләр конфликты ягы булган муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу чаралары муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, эштән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

1.2. 9 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Үзенә буйсынган муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында билгеле булган яллаучының вәкиле булган муниципаль хезмәткәрнең ризасызлыгын, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу чаралары хокук бозу булып тора һәм яллаучының вәкиле булган муниципаль хезмәткәрне, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль хезмәттән эштән азат итүне таләп итә.»;

1.3. 19 статьяга түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт өстәргә:

«1.1. Чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү “Коррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль

законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә, мондый бурычларны үтәмәү аңа бәйле булмаган шартларның нәтиҗәсе дип танылса, муниципаль хезмәткәр чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында федераль законнарда билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә.”

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районының Чытырчы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чытырчы авыл җирлеге башлыгы М.В.Новиков